ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасының закон чыгару эшчәнлеге торышы турындагы доклад хакында

Татарстан Республикасының закон чыгару эшчәнлеге торышы турындагы доклад хакында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтынов чыгышын тыңлап фикер алышканнан соң һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары тәкъдимнәрен гомумиләштереп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының закон чыгару эшчәнлеге торышы турындагы докладны (алга таба – Доклад) хупларга.
2. Докладны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы Рәисенә, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисенә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенә, Россия Федерациясе сенаторларына – Татарстан Республикасыннан вәкилләргә, Татарстан Республикасыннан сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару органнарына, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Аппаратының Хокук идарәсенә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектларга җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларына 2025 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планын төзегәндә Докладтагы тәкъдимнәрне исәпкә алуны тәкъдим итәргә.
4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретаре Л.Н. Мавринага Докладны брошюра рәвешендә татар һәм рус телләрендә бастырып чыгаруны һәм аларның электрон күчермәләрен «Интернет» мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми сайтында урнаштыруны оештырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 11 июле
№ 2562-VI ДС